**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСӘНСЕФ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIV СЕССИЯСЕ**

*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы*

**КАРАР**

*24 март 2025 ел* *№95*

# Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Исәнсеф авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Исәнсеф, Татар Бүләре, Мари-Бүләр, Иске Сәет, Яңа Сәет, Усаклык, Исәнсеф-Чишмә авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:
3. 

Исәнсеф ав., Северная ур., 1а йорт (авыл клубы бинасы);
Татар Бүләре ав., Дуслык ур., 5А йорт (мәдәният йорты бинасы);
Мари-Бүләр ав., Пионер ур., 5А йорт (мәдәният йорты бинасы);
Иске Сәет ав., Совет ур., 35 йорт (ФАП бинасы);
Яңа Сәет ав., Тынычлык ур., 46 й. (кибет бинасы);
Усаклык ав., Урман ур., 2 й. (шәхси йорт);
Исәнсеф-Чишмә ав., Урман ур., 1нче йорт (шәхси йорт).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Исәнсеф авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов